Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегенең Норлат авылында
2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**18 ноябрь 2023ел** **№1/1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегенең Норлат авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Норлат авыл җирлеге торак пункты, Норлат авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I һәм II төркем инвалидларыннан тыш, хәрби бурычны үтәгәндә имгәнгән хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, җирлек территориясендә бер елдан артык яшәмәүче студентлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш балигъ булган һәр кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә булган урам юл челтәрен тоту һәм ремонтлау, шул исәптән бу максатлар өчен инерт, төзелеш материаллары һәм кече архитектура формалары сатып алу, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

2) җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3) урам яктыртуны ремонтлау карап тору, шул исәптән чыгым материаллары һәм комплектлау материаллары сатып алу (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) Тышкы төзекләндерү объектларын (интернационалист сугышчыларга һәйкәлләр, мемориаль такта, контейнер мәйданчыклары, балалар һәм спорт мәйданчыклары) төзү һәм ремонтлау, шул исәптән бу максатлар өчен инертив, төзелеш материаллары һәм кече архитектура формалары сатып алу, смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

5) Беларусь тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (шул исәптән ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

6) Санкцияләнмәгән чүплекләрне чыгару (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

7) Авыл, зират территориясендә агачларны кисү (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

8) Норлат авылының почта урамыннан Норлат зиратына кадәр асфальт япмасын ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

9) Торак пунктта суүткәргеч челтәрен алыштыру (материаллар сатып алу, смета документларын төзү һәм техник контрольне гамәлгә ашыру)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокук мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Аръягы»үзәге бинасы) адреслары буенча кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче Саттаров И.М.